| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Иж-Бобьинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Иж-Бубый авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.02.2024 Иж-Бубый авылы № 40-1

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Әгерҗе муниципаль районының 26.11.2019 елның 50-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Әгерҗе муниципаль районының 26.11.2019 елның 50-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

а) 23 статьяның 3 пункты, 26 статьяның 3 пункты гамәлдә булуын 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының веб-адрес буенча хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р. Р. Ваһапов

Совет Иж-Бобьинского сельского поселения Иж-Бубый авыл җирлеге Советы АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ИНН 1601002460

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниөипалҗ  районы Иж-Бубый авыл җирлеге
Советының 2024 нче елның 18 гыйнварындагы
39-1 номерлы карары белән расланды

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 31.01.2019 елның 43-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге советы карарына кертелә торган ҮЗГӘРЕШЛӘР:

1. 8.11 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга;
2. 8.17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
3. 8.20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"8.20. Муниципаль хезмәткәргә классы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 8.13 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгының барлык кирәкле документлары булган классы чин бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»
4. 13.5 пунктын «Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;
5. 30 бүлекне төшереп калдырырга;
6. 31 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 31.1.1 пункт белән тулыландырырга:
«31.1.1. Муниципаль хезмәт стажы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә »